**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕҺӘМ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**БОЕРЫК**

Казан ш.

____04.07.2017________ ______№420___________

Татарстан Республикасы Яшләр эшләре һәм спорт министрлыгының 2016 елның 28 июлендә кул куелган 460 номерлы боерыгы тарафыннан расланган Татарстан Республикасында физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыра һәм белем бирә торган программаларын гамәлгә куючы оешмаларның педагогика хезмәткәрләренә квалификация категориясе бирү максатында аттестация үткәрүгә дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

**б о е р ы к  б и р ә м:**

Татарстан Республикасы Яшләр эшләре һәм спорт министрлыгының 2016 елның 28 июлендә кул куелган 460 номерлы боерыгы тарафыннан расланган Татарстан Республикасында физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыра һәм белем бирә торган программаларын гамәлгә куючы оешмаларның педагогика хезмәткәрләренә квалификация категориясе бирү максатында аттестация үткәрүгә дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының «Татарстан Республикасында физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыра һәм белем бирә торган программаларын гамәлгә куючы

оешмаларның педагогика хезмәткәрләренә квалификация категориясе бирү максатында аттестация үткәрүгә дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Административ регламентын раслау турында» административ регламентына, аны яңа редакциядә язып, үзгәреш кертергә (кушымтада тәкъдим ителә).

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт
министрлыгының 2016 елның
28 июлендә кул куелган
460_ номерлы боерыгы
(Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт
министрлыгының 2017 елның
4 июлендә кул куелган
420 номерлы боерыгы
редакциясендә) тарафыннан
расланды

**Татарстан Республикасында физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыручы һәм белем бирү программаларын гамәлгә куючы оешмаларның педагогика хезмәткәрләренә квалификация категориясе бирү максатында аттестация үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Административ регламент Татарстан Республикасында физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыручы һәм белем бирү программаларын гамәлгә куючы оешмаларның (алга таба – оешма) педагогика хезмәткәрләренә квалификация категориясе бирү максатында аттестация үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар (алга таба – гариза бирүче): оешмаларның «тренер-укытучы» (өлкәнне дә кертеп) һәм «инструктор-методист» (өлкәнне дә кертеп) вазыйфаларын башкарган, шул исәптән берьюлы шул ук яки башка оешмада вазыйфа башкару, шулай ук шул ук оешмада хезмәт килешүе белән билгеләнгән эш белән беррәттән вазыйфаларны тәңгәл алып барган педагогика хезмәткәрләре (алга таба – педагогика хезмәткәрләре).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан тәкъдим ителә.

1.3.1. Министрлыкның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Казан ш., Петербург ур., 12.

Министрлыкның эш тәртибе: шимбә һәм якшәмбедән кала һәр көнне, дүшәмбе-җомга 9.00 дан алып 18.00га кадәр, төшке аш – 12.30-13.30.

Җәмәгать транспорты белән «Габдулла Тукай мәйданы» («Бožра», «Балалар дөньясы») тукталышына кадәр:

- 1, 29, 30, 31, 35а, 37, 47, 71, 74, 74а, 90, 91 нче автобуслар
- 2, 5, 6, 7, 8, 12, 17 нче троллейбуслар белән
- «Тукай мәйданы» метро станциясенә кадәр килергә мөмкин.

Территориягә бары тик рөхсәт кәгазе һәм (яисә) шәхесне күрсәтә торган документ белән керергә мөмкин.

1.3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе һәм аны башкару барышы турында хәбәр җиткерү Оештыру эше, эш башкару һәм тикшерү бүлеге (алга таба – Бүлек) тарафыннан (843) 222-81-20 телефон номеры аша тормышка ашырыла.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) «Татарстан Республикасының рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмати системасы составына керә торган рәсми сайты адресы: http://mdms.tatarstan.ru/, электрон почта адресы: mdms@tatar.ru

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгъүмат түбәндәге ысуллар буенча алынырга мөмкин:

1) Министрлык биналарында Гариза бирүчеләр белән эшләү өчен урнаштырылган визуаль һәм текст рәвешендәге дәүләт хезмәте турында мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмати стендлар аша;

Мәгълүмати стендларда урнаштырылган мәгълүмат дәүләт хезмәте турындагы әлеге Административ регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (подпунктларында) урын алган мәгълүматларны үз эченә ала.

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://mdms.tatarstan.ru/);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www. gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән (шәхсән яки телефон аша) мөрәҗәгать иткән чакта;

4) Министрлыкка язмача (шул исәптәе электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткән вакытта.

1.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре турындагы мәгълүмат Министрлык хезмәткәрләре тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында һәм Министрлык биналарында урнашкан мәгълүмати стендларда урын ала.

1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге документлар нигезендә тормышка ашырыла:

2010 елның 27 июлендә кабул ителгән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тоткан хәлдә) (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон);

2012 елның 29 декабрендә кабул ителгән «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 53, 7598 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тоткан хәлдә) (алга таба – 273-ФЗ номерлы федераль закон);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 8 августында кабул ителгән «Белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыручы педагогика хезмәткәрләре вазыйфалары, белем бирү оешмалары җитәкчеләре исемлеген раслау турында»

678 номерлы карары («Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, №33, 4381 маддә»);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы тарафыннан 2010 елның 26 августында кабул ителгән «Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләрнең вазыйфалары Бердәм квалификация белешмәлеген раслау турында, «Белем бирү хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация бәяләмәләре» бүлеге» 761н номерлы боерыгы (Российская газета, 2010, 20 октябрь, кертелгән үзгәрешләрне истә тоткан хәлдә) (алга таба – РФ СС һәм СҮМның 761н номерлы боерыгы);

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 7 апрелендә кул куелган «Белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыра торган оешмаларның педагогика хезмәткәрләрен аттестацияләүне үткәрү тәртибен раслау турында» 276 номерлы боерык (Российская газета, 2014, 4 июнь) (алга таба – Аттестацияләү тәртибе);

2013 елның 22 июлендә кабул ителгән «Мәгариф турында» 68-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы хәбәләре, 2013, №7, 977 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тоткан хәлдә (алга таба – Татарстан Республикасының 68-ЗРТ номерлы Законы);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы мәсьәләләре» 315 номерлы карары (алга таба – ТР МК 315 номерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 30, 0695 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тоткан хәлдә);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 880 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, кертелгән үзгәрешләрне истә тоткан хәлдә) (алга таба – ТР МКның 880 номерлы карары).

1.5. Әлеге Административ регламентта түбәндәге терминнар һәм бәяләмәләр кулланыла:

Гариза – 210-ФЗ Федераль законның 2 маддәсе 1 пункты тарафыннан каралган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында сорау (тәкъдим ителгән форма 1нче кушымтада күрсәтелгән)

аттестация – педагогика хезмәткәрләре квалификация дәрәҗәсенең квалификацион категорияләргә (беренче яки иң югары) карата куелган таләпләренә туры килүен билгеләү;

аттестацияне алып бара торган орган – Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы;

аттестация комиссиясе – педагогика хезмәткәрләрен аттестацияләүне үткәрү

өчен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы боерыгы нигезендә төзелгән комиссия;

аттестация комиссиясе карары – комиссиянең аттестация үтәргә тиешле гариза бирүченең гариза бирелгән квалификация категориясенә (беренче яки югары) карата билгеләп куелган таләпләргә туры килүе (туры килмәве) турында фикере;

квалификация категориясе – аттестация үтә торган педагогика хезмәткәре дәрәҗәсенең норматив таләпләргә туры килүен бәяли торган күрсәткеч;

аттестацияләү процедурасы – аттестацияләү процессын тормышка ашыру өчен кирәк булган эзлекле гамәлләрнең билгеләнгән тәртиптә расланган һәм башкару өчен рәсми рәвештә кул куелган стандарт җыелмасы;

техник хата – Министрлык тарафыннан җибәрелеп, документка кертелгән мәгълүматларның (дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе) мәгълүмат нигезендә документларга кертелгән мәгълүматлар белән туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтә урнашкан эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә гариза бирүчеләр белән документларны кабул итү һәм тапшыру, консультация бирү буенча эш алып бара торган тәрәзә (алга таба – КФҮ читтә урнашкан эш урыны).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартының атамасы | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтү яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы | Квалификация категориясе бирү максатларында Татарстан Республикасында физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыручы һәм белем бирү программаларын гамәлгә куючы оешмаларның педагогика хезмәткәрләрен аттестацияләү | 273-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Аттестация үткәрү тәртибе |
| 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) | 273-ФЗ номерлы Федераль законның 49 маддәсенең 3 нче пункты;<br>ТР КМ ның 315 номерлы карары; |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен сурәтләү | Министрлыкның беренче яки югары квалификация категориясе бирү турында боерыгы<br>Аттестация комиссиясенең беренче (югары) квалификация категориясе бирүдән баш тарту турындагы карары (беренче яисә югары квалификация категориясе бирүдән баш тарту турындагы беркетмәдән өземтә) | Аттестация үткәрү тәртибенең 39, 44 пунктлары |
| 2.4. Шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген истә тотып, дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты; әгәр туктатып тору мөмкинлеге | Квалификация категориясе бирү максатларында Татарстан Республикасында физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыручы һәм белем бирү программаларын гамәлгә куючы оешмаларның педагогика хезмәткәрләрен аттестацияләү 90 календарь көненнән дә артык | Аттестация үткәрү тәртибенең 30, 32, 33 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| Россия Федерациясе законнарында каралган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты | булмаган вакытта башкарыла.<br>Педагогика хезмәткәрләренең аттестация үткәрү турында гаризалары аттестация комиссияләре тарафыннан, аны кабул итеп алганнан соң, 30 календарь көн эчендә карала.<br>Аттестация үткәрүнең дәвамлылыгы һәр гариза бирүче өчен аны үткәрү башланганнан алып аттестация комиссия карары кабул итүгә кадәр 60 календарь көненнән дә артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктату каралмый. | |
| 2.5. Гариза бирүче тәкъдим итәргә тиешле законнар һәм башка норматив хокукый актларда каралган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарур һәм мәҗбүри булган хезмәтләр өчен мәҗбүри документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең аларны алу ысуллары, шулай ук электрон формада да, аларны бирү тәртибе | Педагогика хезмәткәрләренә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мәҗбүри документ булып квалификация категориясе билгеләү максатында аттестация үткәрү турында гариза бирүченең гаризасы тора (үрнәк форма 1 нче кушымтада бирелә).<br>Гариза гариза бирүченең игълан ителгән квалификация таләпләренә туры килә торган профессионализм дәрәҗәсен һәм белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләрен үз эченә ала.<br>Гариза аттестация комиссиясенә бирелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын гариза бирүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать итеп алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлык сайтында урнаштырылган.<br>Гариза бирүче гаризаны, кәгазьдә тутырып, түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә тапшыра (җибәрә) ала:<br>шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә гариза бирүче исеменнән эшләүче зат тарафыннан);<br>тапшырылуы турындагы белдерү кәгазе белән | Аттестация үткәрү тәртибенең 27, 30, 36, 37пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | заказлы почта хаты ярдәмендә.<br>Гариза шулай ук көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәре аша һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы законнар һәм башка норматив хокукый актларда каралган мәҗбүри документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада да, аларны бирү тәртибе; карамагында әлеге документлар булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | Министрлыкның аттестация комиссиясендә булган югары квалификация категориясен раслаучы документлардан тыш, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы законнар һәм башка норматив хокукый актларда каралган мәҗбүри документлар юк. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актларда каралган очракларда килештерү таләп итәлә һәм | Дәүләт хезмәт күрсәтүен килештерү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тормышка ашыра торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структура бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мәҗбүри булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | 1. Әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә кергән документны бирмәү.<br>Гариза бирүче биргән документлардагы мәҗбүри мәгълүматларның булмавы. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә аңардан баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:<br>1. Педагогика хезмәткәренең беренче тапкыр аттестация үткәрелә торган әлеге вазыйфасы буенча югары квалификация категориясе бирү максатында аттестация үткәрү турында беренче квалификация категориясе билгеләнгәннән соң ике елдан алдарак гариза бирүе<br>2. Тәкъдим ителгән мәгълүматларның беренче яки югары квалификация категориясе таләпләренә туры килмәве. | Аттестация үткәрү тәртибенең 30, 36, 37, 38 пунктлары |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төр түләүнең тәртибе, күләме һәм алу өчен сәбәп | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү | Зарури һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтүләр таләп | |

| | | |
|---|---|---|
| өчен зарури һәм мәҗбүри булган дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләүнең тәртибе, күләме һәм алу өчен сәбәп, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп. | ителми. | |
| 2.12.Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос биргән вакытта һәм шундый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Кабул итүне (хезмәт күрсәтү) көтүнең максималь вакыты 15 минуттан да артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират тору билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүне, шул исәптән электрон формада да, сорап язган гаризаны теркәү вакыты | Гариза кергән көндә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары белән яраштырып инвалидлар өчен | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар тутыру өчен кирәк булган мебель, мәгълүмати стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен дәүләт хезмәтен күрсәтү урынына тоткарсыз килү (биналарга уңайлы керү-чыгу юллары һәм бина эчендә җайлы йөрү мөмкинлеге).<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, | 880 номерлы карар |

| | | |
|---|---|---|
| мөмкинлекләрне тәэмин итүгә, шундый хезмәт күрсәтүләр тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларга таләпләр | текст һәм мультимедиа рәвешендәге мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы булган урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлек итү саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып мәгълүмат алу мөмкинлегенең уңайлык һәм сыйфат күрсәткечләре. | Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең уңайлылык күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1. кабул итү алып барыла торган биналарның җәмәгать транспорты уңайлы булган зонада урнашуы;<br>2. белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү алып барыла торган биналарның кирәк кадәр санда булуы;<br>3. мәгълүмат стендларында, мәгълүмат ресурсларында һәм «Интернет» челтәрендә дәүләт хезмәтен күрсәтү мөмкинлекләре, тәртибе һәм вакыты турында тулы мәгълүмат булу;<br>4. гаризаны Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге мәгълүмати ресурслары ярдәмендә электрон формада бирү мөмкинлеге;<br>5. документларны кабул итү алып барыла торган биналарның инвалидлар өчен уңайлы булуы;<br>6. башка затлар белән беррәттән хезмәт алуга комачау итә торган киртәләрне җиңүдә инвалидларга ярдәм күрсәтү.<br><br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1. гаризаларны кабул итү һәм карау вакытын саклау; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 2. дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу вакытын саклау;<br>3. дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан җибәрелгән Административ регламентны бозуларга карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булмау;<br>4. гариза бирүченең Министрлык белгечләре белән үзара тәэсир итешү саны:<br>гаризаны турыдан-туры биргән чакта – бердән артмаска тиеш (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>гаризаны һәм документларны почта аша яки электрон рәвештә юллаган очракта – бердән артмаска тиеш (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Гариза бирүче белән үзара тәэсир итешүнең дәвамлылыгы – 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Министрлыкка мөрәҗәгать иткән чакта алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте (шул исәптән дәүләт хезмәтен бирү турында гариза бирү) күпфункцияле үзәктә, КФҮ читтә урнашкан эш урыны аша күрсәтелми. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә гомуми кулланылышта булган мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре, һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр | |

| | | |
|---|---|---|
| | порталы аша тәкъдим итепергә (юлланырга) мөмкин. | |

**3. Административ процедураларның (гамәлләрнын) составы, эзлеклелеге һәм үтәү вакыты, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формадагы административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтә урнашкан эш урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре**

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткән чактагы гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Татарстан Республикасында белем бирү эшчәнлеген һәм квалификация категориясен билгеләү максатында физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган оешмаларның педагогика хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү үз эченә түбәндәге процедураларны ала:

1) гариза язучыга консультация бирү, гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган гаризаны тутыру өлешендә ярдәм күрсәтү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) гаризаны карау һәм аның буенча карар кабул итү;

4) квалификация категориясен (беренче яки югары) билгеләү өчен гариза бирүчегә карата аттестация үткәрү;

5) гариза бирүчене аттестацияләү нәтиҗәләре турында Аттестация комиссиясе карарын раслау;

6) техник хатаны төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 2 нче кушымтада тәкъдим ителде.

3.2. гариза язучыга консультация бирү, гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган гаризаны тутыру өлешендә ярдәм күрсәтү.

Гариза бирүче Бүлеккә шәхсән, телефон аша һәм (яки) почта ярдәмендә (шул исәптән электрон) дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, шул исәптән гариза формасы һәм дәүләт хезмәтен алу өчен кирәк булган башка мәсьәләләр буенча консультация үткәрә. Кирәк булган очракта Бүлек белгече гариза бирүчегә, шул исәпән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган гаризаны тутыру буенча ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнеп куела торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган гаризаны тутыру өлешендә ярдәм күрсәтү.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза бирүче квалификация категориясен билгеләү максатында аттестация үткәрү турында гаризаны Министрлыкка, турыдан-туры аттестация

комиссиясенә, яки аттестация комиссиясе адресына тапшыру турында хәбәр белән почта аша яки, электрон документлар әйләнеше ведомствоара системасын кулланып, электрон документ рәвешендә алу турында хәбәр белән тапшыра.

3.3.2. Бүлек белгече гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документларны кабул итүне, анда булырга тиешле мәҗбүри мәгълүматларның булу-булмавын тикшерүне тормышка ашыра.

Гаризада әлеге Административ регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән мәҗбүри мәгълүматлар булмаган очракта, Бүлек белгече документларны кабул итүдән баш тарта.

Документларны кабул итеп алу өчен сәбәпләр булмаган очракта Бүлек белгече түбәндәге гамәлләрне башкара:

гаризаны терки;

документларны кабул итү көнен күрсәтеп гариза күчермәсен тапшыра (гаризаны шәхсән тапшырган очракта).

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнгән процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үк тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе:

1) документларны кабул итүдән баш тарткан очракта – документларны гариза бирүчегә кире кайтару;
2) кабул итү өчен сәбәпләр булмаган очракта – теркәлгән гариза.

3.4. Гаризаны карау һәм аның буенча карар кабул итү.

3.4.1. Бүлек белгече Аттестация комиссиясе карасын өчен гариза бирүчеләр исемлеген төзи.

Гариза бирүче аттестацияләү процедурасы башланганчыга кадәр үз гаризасын язмача рәвештә кире алырга хокуклы.

Гариза бирүчеләр тарафыннан тәкъдим ителгән гаризалар гаризаны теркәгән көннән алып 25 календар көн дәвамында Аттестация комиссиясе тарафыннан карала.

3.4.2. Гаризаларны карау нәтиҗәсе буенча Аттестация комиссиясе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) гариза бирүчене аңа беренче яки югары квалификация категориясе бирү максатында аттестацияләү үткәрү турында (аттестацияләү үткәрүнең төгәл вакыты һәр гариза бирүче өчен, моңа кадәр билгеләнгән квалификация категориясенең гамәлдә булу вакытын исәпкә алып, шәхсән билгеләнә);

2) гариза бирүчене аңа беренче яки югары квалификация категориясе бирү максатында аттестацияләү үткәрүдән баш тарту турында.

3.4.3. беренче яки югары квалификация категориясе бирү максатында гариза бирүчене аттестацияләү үткәрүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен сәбәпләр әлеге Административ регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән.

3.4.4. Аттестация үткәрү өчен Бүлек белгече:

гариза бирүче турында мәгълүматны квалификация категориясе бирү максатында аттестация узу өчен гариза тапшырган педагогика хезмәткәрләре турындагы Мәгълүмат базасына кертә;

гариза бирүчене педагогика хезмәткәрләрен аттестацияләү графигына кертә;

гариза бирүче турындагы мәгълүматны квалификация категориясе бирү максатында педагогика хезмәткәрләрен аттестацияләүне үткәрү турындагы боерык проектына кертә;

боерык проектын килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнеп куела торган процедуралар 3.4.2. подпункты тарафыннан каралган процедуралар тәмамланган көннән алып өч көн дәвамында тормышка ашырыла, гаризалар килүгә карап ай саен.

Килештерелгән боерык проекты раслау өчен министрга юллана.

Процедура нәтиҗәсе: раслау өчен җибәрелгән боерык.

3.4.5. Министр аттестацияләүне үткәрү турындагы боерыкка кул куя.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнеп куела торган процедура 3.4.4. подпункты тарафыннан каралган процедура тәмамланган көннән алып бер көн дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: расланган боерык.

3.4.6. Бүлек белгече гариза бирүчеләргә язмача хәбәр җиткерә:

1) гариза бирүчегә беренче яки югары квалификация категориясе бирү максаты белән аны аттестацияләү үткәрү турында карар кабул ителгән очракта – аттестацияләүне үткәрү вакыты һәм урынын күрсәтеп аттестацияләүне үткәрү турында расланган боерык.

2) гариза бирүчегә беренче яки югары квалификация категориясе бирү максаты белән аны аттестацияләүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта –мондый карар кабул итүнең сәбәпләре турында.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнеп куела торган процедуралар гаризалар теркәлгән көннән алып 30 календарь көн дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе:

1) гариза бирүчегә беренче яки югары квалификация категориясе бирү максаты белән аны аттестацияләүне үткәрү турында юлланылган боерык.

2) дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп турында юлланган хат.

3.5. Квалификация категориясен (беренче яки югары) билгеләү өчен гариза бирүчегә карата аттестация үткәрү.

3.5.1. Һәр гариза бирүче өчен аттестацияләүне үткәрүнең башыннан алып аттестация комиссиясе карар кабул иткәнчегә кадәрге вакыт 60 календарь көннән артмый.

Беренче квалификация категориясе түбәндәгеләр нигезендә билгеләнә:

1) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 5 августында кабул ителгән «Мәгариф системасын мониторинглауны тормышка ашыру турында» 662 номерлы карары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган мәгариф системасын мониторинглау нәтиҗәләре буенча укучылар тарафыннан белем бирү программаларын үзләштерүнең тотрыклы рәвештә уңай нәтиҗәләре.

2) укучыларда фәнни (интеллектуаль), иҗади, физик тәрбия-спорт эшчәнлегенә карата сәләтләрен ачыклау һәм үстерү.

3) белем бирү сыйфатын үстерү, укыту һәм тәрбияләү ысулларын камилләштерүгә шәхсән өлеш кертү, педагогика коллективларында үз һөнәри

эшчәнлегеңнең гамәли нәтиҗәләре тәҗрибәсе белән уртаклашу, оешмада педагогика хезмәткәрләренең методик берләшмәләре эшендә актив катнашу.

Югары квалификация категориясе түбәндәгеләр нигезендә билгеләнә:

1) оешма тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 5 августында кабул ителгән «Мәгариф системасын мониторинглауны тормышка ашыру турында» 662 номерлы карары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган мәгариф системасын мониторинглау нәтиҗәләре буенча укучылар тарафыннан белем бирү программаларын үзләштерү нәтиҗәләренең уңай динамикасына ирешү;

2) укучыларда фәнни (интеллектуаль), иҗади, физик тәрбия-спорт эшчәнлегенә карата сәләтләрен ачыклау һәм үстерү, шулай ук аларның олимпиадаларда, бәйгеләрдә, фестивальләрдә, ярышларда катнашуы;

3) белем бирү сыйфатын үстерү, укыту һәм тәрбияләү ысулларын камилләштерүгә шәхсән өлеш кертү, яңа белем бирү технологияләрен уңышлы куллану, педагогика коллективларында үзеңнең һөнәри, шул исәптән экспериментал һәм инновацияле эшчәнлегеңнең гамәли нәтиҗәләре тәҗрибәсе белән уртаклашу;

4) оешмада педагогика хезмәткәрләренең методик берләшмәләре эшендә, белем бирү процессын программа-методика белән тәэмин итү эшләүдә, һөнәри бәйгеләрдә актив катнашу.

3.5.2. Аттестация вакытында мөстәкыйль экспертларның эшчәнлеген оештыру өчен Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

гариза бирүчене мөстәкыйль аттестацияләү экспертларын җәлеп итеп үткәрелә торган һөнәри экспертиза үткәрү кирәк булган педагогика хезмәткәрләре составы исемлегенә кертә;

гариза бирүченең белем бирү эшчәнлеге (спорт төре) профилен истә тоткан хәлдә мөстәкыйль аттестацияләү экспертлары составын төзи;

мөстәкыйль аттестацияләү экспертлары өчен урынга чыгуның беренчел графигын әзерли;

гариза бирүченең һөнәри нәтиҗәләренә тышкы яктан экспертиза үткәрүне оештыру турындагы боерык проектын әзерли;

боерык проектын килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнеп куела торган процедуралар 3.4.5. подпункты тарафыннан каралган процедуралар тәмамланган көннән алып биш көн дәвамында тормышка ашырылалар.

Боерыкның килештерелгән проекты раслау өчен министрга юллана.

Процедура нәтиҗәсе: раслау өчен юлланган боерык.

3.5.3. Министр гариза бирүченең һөнәри нәтиҗәләренә тышкы яктан экспертиза үткәрүне оештыру турындагы боерыкка кул куя һәм Министрлыкның Бүлегенә юллый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура 3.5.2. подпункты тарафыннан каралган процедура тәмамланган вакыттан алып бер көн дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: расланган боерык.

3.5.4. Бүлек белгече боерыкны командировкага җибәрү өчен җирлек максатыннан – экспертларга, Министрлыкка караган оешмалар җитәкчесенә, физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә идарәне тормышка ашыра торган җирле үзидарә органнарына гариза бирүчегә һәм аны эш белән тәэмин итүчегә экспертиза үткәрү графигы турында хәбәр итү өчен җибәрә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура 3.5.3 подпункты тарафыннан каралган процедуралар тәмамланган көннән алып ике көн дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчеләрнең һөнәри нәтиҗәләренә тышкы экспертиза үткәрүне оештыру турында экспертларга, Министрлыкка караган оешмалар җитәкчесенә, муниципаль берәмлектә физик тәрбия һәм спорт өлкәсендәге идарәне тормышка ашыра торган җирле үзидарә органнарына боерык.

3.5.5. Мөстәкыйль аттестацияләү эксперты гариза бирүченең һөнәри нәтиҗәләренә тышкы экспертиза үткәрүне оештыру турында боерык тарафыннан билгеләп куелган вакытта гариза бирүченең һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәләренең дәүләт норматив таләпләренә туры килүен тикшерүне тормышка ашыра(шул исәптән электрон рәвештә).

Экспертның нигезле нәтиҗәсе Бүлек белгеченә юллана торган эксперт бәяләмәсенә кертелә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедуралар мөстәкыйль аттестацияләү экспертлар эше графигы нигезендә, гариза бирүчеләрнең һөнәри нәтиҗәләренә экспертиза үткәрүне оештыру турында боерык буенча Министрлыкның  аттестация комиссиясендә карар кабул иткәнчегә кадәр егерме биш көн дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: экспертлар бәяләмәсе.

3.5.6. Бүлек белгече аттестация комиссиясе утырышының көн тәртибен әзерли, аттестация комиссиясе утырышында тыңлау өчентәкъдим ителгән эксперт бәяләмәләрен анализлау нәтиҗәләре буенча документлар пакетын тутыра һәм аларныд игълан ителгән квалификация категориясе таләпләренә туры килү-килмәве турында карар кабул итә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедуралар хезмәткәрнең һөнәри нәтиҗәләренә тышкы экспертиза үткәрү көне белән аттестация комиссиясе утырышын уздыру көне аралыгындагы вакытта тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: аттестация комиссиясе утырышының көн тәртибе, аттестация комиссиясе сәркатибенә бирелгән документлар пакеты.

3.5.7. Аттестация комиссиясе сәркатибе утырыш уздыру урынын һәм вакытын тәгаенләү буенча эш алып бара, аттестация комиссиясе әгъзаларына, экспертларга шуларны хәбәр итә, утырышта катнашырга теләк белдергән гариза бирүчегә дә утырыш уздыру көне һәм урыны турында җиткерә.

3.5.8. Аттестация комиссиясе эксперт төркеменең эксперт бәяләмәсе нигезендә педагогика хезмәткәрләренең игълан ителгән квалификация категориясенә туры килүе (туры килмәве) турында соңгы карар кабул итә.

Аттестация комиссиясе карары нигезендә беркетмә төзелә. Беркетмәгә тавыш бирүдә катнашкан аттестация комиссиясе әгъзалары кул куя.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедуралар комиссия утырышын уздырган көнне тормышка ашырыла.

3.5.9. Комиссия утырышлары аттестация комиссиясе утырышларының Министрлык тарафыннан расланган графигы нигезендә, ләкин гариза бирүчеләрнең һөнәри нәтиҗәләренә карата экспертиза үткәрү процедурасы башланган көннән алып ике айдан да соңга калмыйча, уздырыла. Утырышлар нәтиҗәләре буенча аттестация комиссиясе сәркатибе Бүлек белгеченә аттестация комиссиясенең удай кара буенча аерым, тискәре карар буенча аерым кул куелган беркетмәсен бирә.

Процедуралар нәтиҗәсе: аттестация комиссиясе беркетмәсе.

3.6. Аттестация комиссиясенең гариза бирүчене аттестацияләү нәтиҗәләре турындагы карарын раслау.

3.6.1. Бүлек белгече гариза бирүчегә карата аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән очракта аңа игълан ителгән (беренче яки югары) квалификация категориясе бирү турында боерык проектын әзерли, аттестация комиссиясе беркетмәсеннән игълан ителгән (беренче яки югары) квалификация категориясе бирүдән баш тарту турында өземтә әзерли, һәм килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедуралар 3.5.11 подпункты тарафыннан каралган процедуралар тәмамланган көннән алып өч көн дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: педагогика хезмәткәренә игълан ителгән (беренче яки югары) квалификация категориясе бирү турында боерык проекты, аттестация комиссиясе беркетмәсеннән игълан ителгән (беренче яки югары) квалификация категориясе бирүдән баш тарту турында өземтә.

3.6.2. Министрның беренче урынбасары боерык проектын килештерә һәм раслау өчен министрга юллый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура 3.6.1. подпункты тарафыннан каралган процедуралар тәмамланган вакыттан алып бер көн дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: раслау өчен министрга юлланган боерык проекты, аттестация комиссиясе беркетмәсеннән игълан ителгән (беренче яки югары) квалификация категориясе бирүдән баш тарту турында өземтә.

3.6.3. Министр педагогика хезмәткәренә игълан ителгән (беренче яки югары) квалификация категориясе бирү турында боерыкны раслый һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура 3.6.2. подпункты тарафыннан каралган процедуралар тәмамланган вакыттан алып бер көн дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: расланган боерык, аттестация комиссиясе беркетмәсеннән игълан ителгән (беренче яки югары) квалификация категориясе бирүдән баш тарту турында өземтә.

3.6.4. Бүлек белгече түбәндәге эш-гамәлләрне башкара:

Гариза бирүчегә югары (беренче) квалификация категориясе бирү турында

боерыкны физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә идарә итүне тормышка ашыра торган җирле үзидарә органына, гариза бирүчегә хезмәт хакының тиешле дәрәҗәсен билгеләү өчен оешмага юллый;

аттестация комиссиясе беркетмәсеннән гариза бирүчегә югары (беренче) квалификация категориясе бирүдән баш тарту турында беркетмәдән алынган өземтәне юллау.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура 3.6.3. подпункты тарафыннан каралган процедуралар тәмамланган вакыттан алып өч көн дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: юлланган боерык, аттестация комиссиясенең гариза бирүчегә югары (беренче) квалификация категориясен бирүдән баш тарту турында беркетмәсеннән юлланган өземтә.

3.7. Техник хатаны төзәтү

Югары (беренче) квалификация категориясе бирү турында боерыкны яңадан теркәү югары (беренче) квалификация категориясен билгеләү турындагы боерыкта (алга таба – Боерык) җибәрелгән техник хаталарны (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата) юкка чыгару белән бәйле рәвештә тормышка ашырыла.

Боерыкны яңадан теркәү техник хата киткән Боерык белән бергә бирелгән теркәлгән гариза (тәкъдим ителгән форма 3нче кушымтада бирелде) нигезендә тормышка ашырыла.

3.7.1. Бүлек белгече түбәндәге гамәлләрне башкара:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм терки;

электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша электрон формада техник хатаны төзәтү турында гаризаны министрга җибәрә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура техник хатаны төзәтү турында гариза теркәлгән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм министрга юлланган техник хатаны төзәтү турындагы гариза.

3.7.2. Министр техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны карый һәм карап чыгу өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура техник хатаны төзәтү турында гариза теркәлгән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: карап чыгу өчен министрның беренче урынбасарына юлланган техник хатаны төзәтү турында гариза.

3.7.3. Министрның беренче урынбасары техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны карый һәм карап чыгу өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура техник хатаны төзәтү турында гариза теркәлгән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: карап чыгу өчен Бүлек башлыгына юлланган техник хатаны төзәтү турында гариза.

3.7.4. Бүлек башлыгы Бүлек белгечен билгели һәм башкару өчен аңа техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны тапшыра.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура техник хатаны

төзәтү турында гариза теркәлгән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: башкару өчен Бүлек белгеченә юлланган техник хатаны төзәтү турында гариза.

3.7.5. Бүлек белгече:

яңа редакциядә Боерык проектын һәм хат проектын әзерли һәм килештерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

3.7.6. Бүлек башлыгы яңа редакциядә әзерләнгән Боерык проектының дөреслеген тикшерә һәм килештерү өчен аны министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура яңа редакциядәге Боерык проекты һәм хат проектының килештерү өчен  Бүлек башлыгына килгән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юлланган хат һәм Боерык проектлары.

3.7.7. Министрның беренче урынбасары яңа редакциядәге Боерык белән бергә юллана торган гариза бирүчегә аталган хат проектын килештерә һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура Бүлек башлыгыннан хат проекты килгән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: яңа редакциядәге Боерык белән бергә юллана торган килештерелгән хат проекты.

3.7.8. Бүлек белгече килештерелгән хат проектын һәм яңа редакциядәге Боерыкны министрга юллый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура хат проектын һәм яңа редакциядәге Боерыкны министрның беренче урынбасары килештергән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: имзалау өчен министрга юлланган хат проекты һәм яңа редакциядәге Боерык проекты.

3.7.9. Министр гариза бирүчегә хат проектын һәм яңа редакциядәге Боерык проектын имзалый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура хат проектының имзалау өчен министрга юлланган көненнән алып бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: министр тарафыннан имзаланган гариза бирүчегә аталган хат һәм яңа редакциядәге Боерык.

3.7.10. Бүлек белгече түбәндәге гамәлләрне башкара:

гариза бирүчегә хатны һәм аңа югары (беренче) квалификация категориясе бирү турында яңа редакциядәге боерыкны физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә идарә итүне тормышка ашыра торган җирле үзидарә органына, гариза бирүчегә хезмәт хакының тиешле дәрәҗәсен билгеләү өчен оешмага юллый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура 3.7.9. подпункты тарафыннан каралган процедуралар тәмамланган вакыттан алып бер көн дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юлланган хат һәм югары (беренче) квалификация категориясен билгеләү турындагы боерык.

3.8. Күпфункцияле үзәк, КФҮ читтә урнашкан эш урыны аша дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе.

Дәүләт хезмәте (шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза бирү) күпфункцияле үзәк, КФҮ читтә урнашкан эш урыны аша күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне тикшерү тәртибе һәм рәвеше

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Административ регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка төр норматив хокукый актларны үтәүне һәм башкаруны, шулай ук җаваплы затлар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы тикшерү Бүлек башлыгы тарафыннан тормышка ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатлылыгын тикшерү үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукын бозуны ачыклау һәм юкка чыгаруны, шикаятьләрне карау, карар кабул итү һәм гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләренә җавап әзерләүне ала.

Административ процедураларн үтәүне тикшерү формалары булып түбәндәге тикшерүләрне үткәрү тора:

эш башкаруны алып баруны;

документларны карау нәтиҗәләренең законнар (әлеге Регламент) таләпләренә туры килүен;

документларны кабул итү вакытларын һәм тәртибен үтәүне;

дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта нәтиҗәләрне юллау вакытларын һәм тәртибен үтәүне.

Тикшерүләр үткәрүнең кабатланып торуы планлы (эш планы нигезендә уздырыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең аерым мөрәҗәгате буенча) характерда була.

4.2. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозган очракларны ачыклаган чакта гаепле дип танылган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.3. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерү дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләр (шикаятьләр) карауның судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат бирү юлы белән тормышка ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органнарның, шулай ук вазыйфаи затлары һәм дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамьсезлегенә) судка кадәр (судтан тыш) дәгъва бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучыларның Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә Министрлыкның дәүләт хезмәткәренең гамәлләренә (гамьсезлегенә)

карата судка кадәр – Министрлыкка дәгъва бирү хокукы бар. Министр тарафыннан кабул ителгән дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле карарларга шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Гариза бирүче түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән:

- дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү вакытын бозган очракта;
- дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытын бозганда;
- гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документларны таләп иткәндә;
- гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүне кире каккан чакта;
- әгәр кире кагу өчен нигезләмәләр федераль законнар, аларга бәйле кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне кире какканда;
- дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү кертүне таләп иткән очракта;
- Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар яисә хәреф хаталарын төзәтүдән баш тарткан яисә шундый төзәтүләрның билгеләнгән вакытын бозган чагында.

5.2. Шикаять язмача рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге аша, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mdms.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең (функцияләре) бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчедән шәхси кабул итү вакытында кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне дәвамында. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган вазыйфаи зат гариза бирүчедән документлар кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталар һәм хәреф хаталарын төзәтүдән баш тарткан очракта, яисә андый төзәтүләрне билгеләнгән вакытны бозу буенча шикаять биргән очракта – аны теркәгәннән соң биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарлары яисә гамәлләренә (гамьсезлегенә) карата шикаять бирелә торган дәүләт хезмәтен күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның вазыйфаи заты, яки дәүләт хезмәткәре атамасы;

2) гариза бирүче – физик затның исеме, фамилиясе, атасының исеме (булган очракта), тору урыны турында белешмә, гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон

почта (булган очракта) адресы (адреслары) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның вазыйфаи заты, яки дәүләт хезмәткәренең дәгъвалана торган карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлеге) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәтен күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның вазыйфаи заты, яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамьсезлеге) белән килешмәү өчен нигез булып торган дәлилләр.

5.5. Шикаять белән бергә анда күрсәтелгән хәлләрне раслый торган документ күчермәләрен дә тәкъдим итәргә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аның белән бергә бирелә торган документлар исемлеге тәкъдим ителә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәтен алучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча министр (министрның беренче урынбасары) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәтен күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән хаталар һәм хәреф хаталарын төзәтү, гариза бирүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында түләтү каралмаган акча чараларын кире кайтару формасында, шулай ук башка формаларда;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге Административ регламентның 5.7 подпунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә язмача рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

Шикаятьне карау барышында яисә аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы яисә җинаять билгеләре ачыкланган очракта шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләре булган вазыйфаи зат тиз арада булган материалларны прокуратура органнарына җибәрә.

Татарстан Республикасында физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыручы һәм белем бирү программаларын гамәлгә куючы оешмаларның педагогика хезмәткәрләренә квалификация категориясе бирү максатында аттестация үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Административ регламентына
1нче кушымта
(тәкъдим ителгән форма)

______________________________________
(кая – аттестация комиссиясе атамасы)

______________________________________
______________________________________
(кемнән – фамилия, исем, атасының исеме)

______________________________________
(вазыйфасы, эш урыны)

ГАРИЗА

Миңа 20___ елда ____________________________________ вазыйфасы (вазыйфалары) буенча ____________________квалификация категориясенә аттестацияләвегезне сорыйм. ___________________________________________________.

Хәзерге вакытта _______________________ вазыйфасы буенча _______________ квалификация категорияенә иямен, аның гамәлдәге вакыты _________________________________
гамәлдә булу көне, ае, елы тәмамланган көне

яки квалификация категориям юк.

Гаризада күрсәтелгән квалификация категориясенә аттестация үтү өчен нигез булып ____________квалификация категориясенә[1] куела торган тиешле таләпләргә туры килә торган түбәндәге эш нәтиҗәләрен күрсәтәм: ___________________________________________________.

Үзем турында түбәндәге мәгълүматны җиткерәм:

Белемем (кайчан һәм нинди уку йортын тәмамлаганлыгы, нинди белгечлек һәм квалификация алганлыгы) _________________________________________________________ ___________________________________________________________________________

педагогик эшчәнлек стажы (белгечлек буенча) ________ ел, әлеге вазыйфада ___________ ел; әлеге оешмада _____________ ел.

Түбәндәге бүләкләргә, исемнәргә, фәнни дәрәҗәгә, гыйльми исемгә иямен: ___________________________________________________________________________.

Квалификация күтәрү турында мәгълүмат (курсларда укыту кайчан һәм кайда уздырылган, сәгатьләр саны, тематикасы, раслый торган документ) ___________________________________________________________________________.

Аттестацияне атестацияләү комиссиясе утырышында минем катнашта (минем катнашымнан башка) (кирәклесенең астына сызарга) уздыруны сорыйм.

Белем бирү оешмаларының педагогика хезмәткәрләрен аттестацияләү тәртибе белән таныштым, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризамын:


«____» _____________________ 20___ г. Имза _______________________


Кәрәзле телефон __________________, Эш телефоны _______________

[1] Эш нәтиҗәләре турында мәгълүмат гаризага кушымта буларак килергә мөмкин.

Татарстан Республикасында физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыручы һәм белем бирү программаларын гамәлгә куючы оешмаларның педагогика хезмәткәрләренә квалификация категориясе бирү максатында аттестация үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Административ регламентына
2нче кушымта

**Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы**




Аттестация комиссиясе сәркатибе Комиссия утырышын әзерләү буенча эш алып бара
Комиссия әгъзаларына утырыш көне турында хәбәр җиткерү
Аттестация комиссиясе игълан ителгән квалификация категориясенә туры килү (туры килмәү) турында соңгы карар кабул итә.
Аттестация комиссиясе беркетмәсе
әйе
Категория бирү турында карар кабул ителә
юк
Белгеч Игълан ителгән квалификация категориясен бирү турында боерык проектын әзерли
Белгеч Беркетмәдән игълан ителгән категорияне бирүдән баш тарту турында өземтә әзерли
Министрның беренче урынбасары Боерыкны килештерә
Министрның беренче урынбасары Өземтәне килештерә
Министр Боерыкка кул куя
Министр Беркетмәдән алынган өземтәгә кул куя
Белгеч Квалификация категориясен бирү турында боерыкны юллый
Белгеч Гариза бирүчегә игълан ителгән категорияне бирүдән баш тарту турында өземтә юллый.
Юлланган боерык
Гариза бирүчегә юлланган өземтә

Татарстан Республикасында физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыручы һәм белем бирү программаларын гамәлгә куючы оешмаларның педагогика хезмәткәрләренә квалификация категориясе бирү максатында аттестация үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Административ регламентына
3нче кушымта

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт министры
В.А.Леоновка

___________________________________________

(оешма атамасы, оешма җитәкчесе яки оешма вәкиленең ФИАи)

___________________________________________

Техник хатаны төзәтү турында
ГАРИЗА

__________________________________________ боерыкта җибәрелгән хата
боерык реквизитлары

турында хәбәр итәм. ______________________________________________________

күрсәтелгән. Дөрес белешмәләр: ______________________________________________

__________________________________________________________________________.

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган боерыкка тиешле үзгәрешләрне кертүегезне үтенәм.

Түбәндәге документларны тәкъдим итәм:

1.

2.

Документның әзер булуы турында миңа хәбәр итүегезне сорыйм.

__________________________________________________________________________
(хәбәр итү юлы)

_______________ _______________ (_______________________)
(дата) (имза) (имзаны ачыклау)

Татарстан Республикасында физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыручы һәм белем бирү программаларын гамәлгә куючы оешмаларның педагогика хезмәткәрләренә квалификация категориясе бирү максатында аттестация үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Административ регламентына
4нче кушымта

**Татарстан Республикасында физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыручы һәм белем бирү программаларын гамәлгә куючы оешмаларның педагогика хезмәткәрләренә квалификация категориясе бирү максатында аттестация үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнарның һәм вазыйфаи затларның реквизитлары**

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр Леонов Владимир Александрович | (843) 222-81-01 Факс: (843) 222-81-79 | ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы – В.А.Леоновның кабул итү бүлмәсе Priemnaya.RT@tatar.ru http://mdms.tatarstan.ru/ |
| Министрның беренче урынбасары Шәйхетдинов Хәлил Хәмит улы | (843) 222-81-03 Факс: (843) 222-81-79 | ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы – Х.Х.Шәйхетдиновның кабул итү бүлмәсе Priemnaya.RT2@tatar.ru |
| Бүлекнең әйдәп баручы киңәшчесе Семенова Юлия Анатольевна | (843) 222-81-18 | Yuliya.Kotelova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге | (843) 264-77-01 | enter@kabmin.tatarstan.ru |